ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2025 елда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры хисабы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры хисабын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары белән берлектә «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында комплекслы чараларны гамәлгә ашыруны дәвам итүне.

2.2. 2026 елда Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны, башка массакүләм чараларны әзерләү һәм үткәрү чорында җәмәгать тәртибен һәм иминлек тәэмин итүне.

2.3. Татарстан Республикасы гавами хакимият органнары, иҗтимагый берләшмәләр, традицион конфессияләрнең дини оешмалары, милли-мәдәни автономияләр белән берлектә экстремистлык һәм террорчылык эшчәнлегенә каршы көрәш өлкәсендә, аеруча мөһим инфраструктура объектларына һәм яшәүне тәэмин итү объектларына карата, чараларны, ихтимал булган милләтара конфликтларны булдырмау чараларын үткәрүне дәвам итүне.

2.4. Татарстан Республикасы шәһәрләрендә һәм башка торак пунктларында җәмәгать тәртибен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрүне, шул исәптән гражданнар оборонасы өлкәсендә чаралар үткәргәндә Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларыннан килгән зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе белән берлектә, дәвам итүне.

2.5. Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар арасында законсыз миграциягә һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш максатларында Татарстан Республикасында миграция вазгыятен тикшереп тору өлешендәге эшне дәвам итүне.

2.6. Наркоҗинаятьчелекнең оешкан рәвешләренә каршы тору, яшерен нарколабораторияләр эшчәнлеген туктату, наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорларын китерү каналларын ябу буенча чаралар күрүне, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, арттыруны.

2.7. Мәгълүмат технологияләрен, шул исәптән ясалма интеллект, кулланып кылына торган җинаятьләрне профилактикалау механизмнарын камилләштерү чараларын күрүне дәвам итүне.

2.8. Балигъ булмаганнарны җинаять эшчәнлегенә тартуга каршы көрәш максатларында алар арасында хокук бозуларны профилактикалау эшен көчәйтүне.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру һәм аны үз вакытында финанслау эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

4. Җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Муниципаль берәмлекләр территорияләрендә җәмәгать тәртибен саклауны һәм гражданнарның иминлеген оештыру буенча хокук саклау органнары белән хезмәттәшлекне арттыруны.

4.2. Хокук саклау юнәлешендәге (экстремистлык һәм террорчылык күренешләренә каршы көрәш, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, хокук бозуларны профилактикалау өлкәләрендәге) муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны һәм аларны үз вакытында финанслауны, шулай ук әлеге программаларның эчтәлеген, «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезләмәләрен исәпкә алып, актуальләштерүне тәэмин итүне.

4.3. Балаларның, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең мәшгульлеген тәэмин итүне оештыру максатларында аларны физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен шартлар тудыру чараларын күрүне.

5. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгына Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә массакүләм мәгълүмат чараларында гражданнарның шәхси иминлеге, аларның акчаларын һәм мөлкәтен саклау мәсьәләләрен аңлатучы, экстремистлык һәм террорчылык юнәлешендәге

җинаятьләр әзерләнү яисә кылыну турында билгеле булган фактлар хакында хокук саклау органнарына хәбәр итү ысуллары турында белешмәләр, шулай ук халыкта эчке эшләр органнары эше хакында уңай фикер тудыра торган материаллар бастырып чыгару эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2026 елның 19 феврале
№ 538-VII ДС